## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге составына керүче Шәмәк торак пунктында 2021 елга үзара салым кертү турында

№ 1 11.11. 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлегенең Шәмәк торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Шәмәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 500(биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Шәмәк торак пунктына янгын гидрантлары җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру;
- Шәмәк авыл мәдәният йорты территориясен койма белән әйләндереп алу (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Шәмәк торак пунктында вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Шәмәк торак пунктындагы юлларны кардан чистарту

3. Әлеге карарны Шәмәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Шәмәк авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе И.Н.Зиятдинов